КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 793

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 июль, 597 нче; 2023 ел, 7 июнь, 692 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 12 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«12. Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарылган эшләргә һәм куллана торган төзелеш материалларына экспертиза ясау, тикшерү, лаборатория һәм башка сынауларны үткәрү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин